КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 1 август г.Казань № 641

Гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен сәнгать-анимация басмалары чыгаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) сәнгать-анимацион басмалар чыгаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен сәнгать-анимация басмалары чыгаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 1 август, 641 нче карары
белән расланды

Гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен сәнгать-анимация басмалары чыгаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен сәнгать-анимация басмалары чыгаруга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба – субсидияләр).

2. Субсидияләр әлеге Тәртип нигезендә сайлап алынган коммерциячел булмаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) (алга таба - оешма) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен сәнгать-анимация басмалары чыгаруга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү максатларында бирелә.

Әлеге Тәртиптә сәнгать-анимация басмалары дигәндә китап рәвешендәге кәгазь басмадан, шулай ук интерактив уеннар-биремнәр, фото- һәм видеоматериаллар, җырлардан һәм сайтта һәм мобиль кушымтада китап сюжеты буенча бүтән өстәмә материаллардан торган сайт һәм мобиль кушымтан гыйбарәт кече яшьтәге мәктәп балалары өчен нәфис әсәр аңлашыла.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче булып, Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә, бюджет акчаларын алучы буларак тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тора.

4. Субсидияләр вәкаләтле органга чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларга бирелә.

5. Субсидия алучылар категориясе - Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимацион басмалар эшләүне һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы, әлеге Тәртип нигезендә сайлап алынган коммерциячел булмаган оешма, дәүләт (муниципаль) учреждениесеннән тыш.

6. Субсидияләр түбәндәге таләпләргә туры килә торган оешмаларга бирелә:

сәнгать-анимацион басмалар эшләү һәм эшләп чыгару;

законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә:

субсидия алучы салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләргә ия түгел;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары юк;

үзгәртеп кору, бетерү процессында тормыйлар, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгел;

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып дәүләт яки территория торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмый торган чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында дәүләт яки территория булып торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган счалым салуның ташламалы салым режимын;

Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алучылар булып тормый.

7. Оешмаларны сайлап алу критерийлары:

оешма эшчәнлегенең төп төре - нәшрият эшчәнлеге;

субсидия алу өчен гариза бирү көненәтиешле эшчәнлек өлкәсендә биш елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе бар;

нәфис-анимацион басмалар чыгаруга аерым хокукларга ия;

сәнгать-анимацион басманың эскиз-проекты тәкъдим ителгән.

8. Субсидия алу өчен оешма вәкаләтле органга түбәндәге документлар тапшыра:

оешма җитәкчесе яисә билгеләнгән тәртиптә башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган субсидия бирүгә вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча гариза;

сәнгать-анимацион басманың эскиз-проекты, китап эскизын, сайтта, мобиль кушымтада урнаштыру өчен анимацион материаллар проектын да кертеп;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү турында документлар күчермәләре;

дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;

субсидия алучы салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләргә ия түгел;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары

юклыкныраслый торган документ;

оешма җитәкчесе яисә башка билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган, оешманың үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмауны раслый торган гарантия хаты;

оешма Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алучы булып тормауны раслый торган документ.

нәфис-анимацион басмалар эшләү һәм чыгару белән бәйле оешмаларның планлаштырылган чыгымнары турында документлар:

авторлык килешүләре, сәнгать-анимацион басмаларга аерым хокукларны читләштерү турында шартнамәләр;

нәфис-анимацион басмалар эшләү һәм чыгару өчен чыгымнар сметасы;

калькуляция (исәп-хисап һәм бәяләрне нигезләү белән).

9. Гаризалар кабул итүне башлау һәм тәмамлау вакыты, гаризаларны карау графигы, оешманы сайлап алуны гамәлгә ашыручы конкурс комиссиясе составы 5 кешедән дә ким булмаган санда (алга таба – Комиссия) вәкаләтле орган боерыгы белән раслана. Әлеге мәгълүмат вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында гаризалар кабул ителә башлаганчы 3 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Комиссия составына вәкаләтле орган вәкилләре, филология өлкәсендәге белгечләр, балалар психологы, логопед, беренче һәм югары квалификация категориясенә ия укытучылар, галимнәр, язучылар һәм башка белгечләр керә ала.

10. Вәкаләтле орган теркәлгән документлар белән гаризаларны кабул итә һәм алар кергән көннән соң бер көн эчендә терки.

11. Комиссия эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә гаризаларны карап тикшерә һәм күрсәтелгән срокта сайлап алуда җиңүче турында карар кабул итә.

Конкурс сайлап алу критерияләре буенча гаризаларны бәяләү Комиссия тарафыннан балларда башкарыла. Гаризаларны карау тәртибе һәм сайлап алу критерийларының мәгънәләре вәкаләтле орган боерыгы белән билгеләнә һәм гаризаларны кабул итә башлаганчы 5 календарь көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле органның рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Конкурс бәяләүләре буенча иң күп балл җыйган оешма Конкурс сайлап алуында җиңүче дип таныла.

Оешмалар тәкъдим иткән нәфис-анимацион басманың эскиз-макеты шулай ук максатчан аудиториянең (кече мәктәп яше) яшенә, сайтка һәм мобиль кушымтага куркынычсыз керү параметрларына, кече мәктәп яшендәге балалар өчен сәнгать-анимация басмаларына куела торган таләпләргә туры килү-килмәү предметына бәяләнә.

Комиссия карары мондый карар кабул ителгән көнне вәкаләтле органга җибәрелә. Вәкаләтле орган Комиссия карары кабул ителгәннән соң 2 эш көненнән дә соңга калмыйча субсидия бирү яки оешмага субсидия бирүдән баш тарту турында боерык рәвешендә карар кабул итә.

Комиссия гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча оешмалар тарафыннан әлеге Тәртип таләпләренә туры килә торган документларның тулы пакеты тапшырылса һәм

бер үк вакытта нәфис-анимацион басманың эскиз проектын караганда бер үк санда балл җыйсалар, сайлап алу җиңүчесе дип гаризаны вәкаләтле органга элегрәк биргән оешма санала (датасы бөуенча, кирәк булганда, аның керү вакыты буенча).

Вәкаләтле орган, шундый ук хезмәт күрсәтүләргә базар бәяләрен чагыштыру юлы белән, документларда күрсәтелгән чыгымнарның нигезле булуын тикшерә.

12. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

оешманың әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 8 пунктында билгеләнгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

оешма тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

тиешле финанс елына бюджет финанславы лимитлары булмау.

13. Кабул ителгән карарның нәтиҗәләре турында хәбәрнамә оешманың вәкаләтле органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән соң бер көн эчендә язма рәвештә җибәрелә.

14. Субсидия бирү вәкаләтле орган һәм аңа карата субсидия бирү турында карар кабул ителгән оешма (алга таба – субсидия алучы) арасында субсидия бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турындагы килешү, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелгән ике көн эчендә төзелә.

Субсидия бирү турында килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар төрләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидия алучының субсидиядән файдалану турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирү буенча йөкләмәсе әлеге Тәртипнең 20 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда;

килешүне вакытыннан алда туктату өчен нигезләр;

субсидия күләме;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмый калган (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта) субсидияләрне кире кайтару очраклары;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләр калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, вәкаләтле орган тарафыннан аларны куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәнд;

субсидия алучының вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

алына торган акчалар исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү очрагында) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган

операциялӓрдӓн тыш;

шартнамӓлӓр (килешүлӓр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затлар белән шартнамәләргә (килешүләргә) кертү турында субсидия алучының йөкләмәсе вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерү һәм алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән сатып алуны тыю турында, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән баш бүлүчегә бюджет акчаларын алучы буларак субсидияләр бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта да;

субсидия алучы белән килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю;

бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче белән килешүне берьяклы өзү өчен нигезләр;

вәкаләтле орган, бюджет акчаларын алучы буларак, килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, субсидия алучы тарафыннан тотылган чыгымнарны бюджет акчаларын алучы буларак вәкаләтле орган тарафыннан каплау тәртибе;

субсидия алучыга хезмәт күрсәтү өчен кирәкле эшләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тыш, аңа субсидия бирелә торган хезмәтләр күрсәтү өчен субсидия алучы тарафыннан башка юридик затларны җәлеп итүгә тыю;

субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмә.

Субсидия бирү турындагы килешүдә вәкаләтле органның, бюджет акчаларын алучы буларак, субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм рәвешләрен билгеләү хокукы карала.

15. Субсидия бирү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

чыгарылган нәфис-анимацион басмалар саны (данә);

нәфис-анимацион басмаларны чыгару срокларын үтәү (процентларда).

Субсидияләр бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

16. Нәфис-анимацион басмалар чыгаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр күләме вәкаләтле органга нәфис-анимацион басмалар чыгаруга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә, шулай ук вәкаләтле орган белән килештерелгән оешманың чыгымнарының башлангыч сметасын исәпкә алып билгеләнә.

17. Сәнгать-анимация басмаларын эшләү һәм чыгару белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр (С) күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = Е_1 + Е_2 + Е_3 + Е_4 + Е_5 + Е_6 + Е_7 + Е_8,$$

монда:

$Е_1$ - нәфис-анимацион басма макеты ясау чыгымнары һәм редакция хезмәтләре,

сум;

$E_2$ – архив материалларын, компьютер графикасын, компьютер графикасын куллану чыгымнарыннан тыш, авторлык һәм чиктәш хокуклар буенча түләүгә чыгымнар, сумнар;

$E_3$ - штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләргә түләү чыгымнары, сум;

$E_4$ – бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәре, производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләү буенча кетемнәр, дәүләт пошлиналары, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри кертемнәр һәм түләүләр күләме, сум;

$E_5$ – типография һәм полиграфия хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар, сәнгать-анимацион басманы китерүгә (транспортлауга) чыгымнар;

$E_6$- биналарны арендага алу, техник чаралар сатып алу, коммуналь хезмәтләр өчен түләү, элемтә хезмәтләре өчен түләү, программа белән тәэмин итү чыгымнарын түләү (бухгалтерия программалары, вируска каршы программалар, электрон хисаплылык);

$E_7$ – канцелярия һәм чыгым материаллары, инвентарь, комплектлау һәм җиһазлар өчен чыгым өлешләрен сатып алуга, шул исәптән җиһазларны ремонтлауга чыгымнар;

$E_8$ - банк хезмәтләренә чыгымнар.

Субсидия күләме вәкаләтле органга чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларга расланган бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артып китә алмый.

18. Вәкаләтле орган субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнелгән 10 көн эчендә субсидияне субсидия алучыларның Россия кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына, әлеге Тәртип нигезендә төзелгән килешү булганда, күчерә.

19. Субсидия алучылар субсидияләр керү һәм аларны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып баралар.

20. Субсидия алучылар әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә формалар бөуенча субсидия бирелгән елның 15 декабренә кадәр вәкаләтле органга субсидиядән файдалану турында хисап һәм субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү турында оешма җитәкчесе яисә башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган кәгазьдә, йә оешма җитәкчесенең электрон имзасы белән имзаланган электрон формада хисап тапшыралар.

21. Субсидияләр вәкаләтле органның тиешле таләбе алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш:

вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру, субсидия алучы тарафыннан аларны биргәндә куелган шартлар бозылу очраклары ачыкланганда тулы күләмдә;

субсидияләрдән файдалану турында хисап һәм (яки) субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшырмаган очракта, хисап тапшыру срокларын бозган очракта, тулы күләмдә;

субсидия акчаларыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта,

максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә;

нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең һәр ирешелмәгән күрсәткече өчен биш процент күләмендә.

22. Хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләр алучылар тарафыннан субсидияләр бирү турындагы килешүдә каралган очракларда, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

23. Әлеге Тәртипнең 20 һәм 21 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару срокларын бозганда, вәкаләтле орган, субсидияләрне кире кайтару срогы чыккан көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

24. Законнар нигезендә вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерә.

25. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.